УДК 398.8

*Л.Х. Дәүләтшина*

# ТАТАР ЙОЛА ФОЛЬКЛОРЫНЫҢ БҮГЕНГЕ ЯШӘЕШЕ: СОЛДАТКА ОЗАТУ ЙОЛАСЫ

Статья посвящена комплексному анализу обряда проводов в армию *(солдатка озату йоласы)* как культурного феномена, раскрывающего его историческую эволюцию, структуру и семантику. Научная новизна работы заключается в исследовании обряда как целостного комплекса, объединяющего ритуальные практики, фольклорные тексты (рекрутские песни, поверья) и мифологические верования. В научный оборот вводятся опубликованные источники и неопубликованные полевые материалы автора, демонстрирующие трансформацию обряда от эпохи рекрутчины до современности. Исследование показало, что ядро ритуала составляют уличные обходы с исполнением рекрутских песен; магические практики при уходе рекрута из дома, ритуальная трапеза (каша, хлеб и др.), а также символика границ, проявляющаяся в преодолении порога и прощании у ворот деревни. В заключении подчеркивается, что исследуемый обряд представляет собой устойчивый комплекс, функционирующий в фольклорной традиции по сей день и сохраняющий основную структуру и семантику в условиях меняющегося мира.

**Ключевые слова:** фольклор, традиция, татарская фольклористика, переходные обряды, рекрутский обряд, проводы в армию.

The article is devoted to a comprehensive analysis of the ceremony of sending off to the army (Soldatka Ozatu Yolasi) as a cultural phenomenon, revealing its historical evolution, structure and semantics. The scientific novelty of the work lies in the study of the rite as an integral complex combining ritual practices, folklore texts (recruitment songs, beliefs) and mythological beliefs. Published sources and unpublished field materials of the author are introduced into scientific circulation, demonstrating the transformation of the rite from the era of recruitment to the present. The study showed that the core of the ritual consists of street rounds with the performance of recruit songs; magical practices when a recruit leaves home, a ritual meal (porridge, bread, etc.), as well as the symbolism of borders, manifested in crossing the threshold and saying goodbye at the village gates. In conclusion, it is emphasized that the ritual under study is a stable complex that functions in the folklore tradition to this day and preserves the basic structure and semantics in a changing world.

**Keywords:** folklore, tradition, Tatar folklore studies, transitional rites, recruitment ceremony, sending off to the army.

Ир-егетләрне хәрби хезмәткә озату йоласы (рекрут йоласы) татар халкының традицион мәдәниятендә зур урын алып тора һәм ил тарихы белән бәйле вакыйгаларга барып тоташа. Фәнни әдәбиятта рекрут йоласының барлыкка килүе регуляр армия булдырган Пётр I заманына нисбәт ителә [5: 13]. Бу вакыйга 1705 елда егетләрне рекрутлыкка җыю турында указ чыгуга бәйле. Шуның нәтиҗәсе буларак, 1722 елдан татарларны да хәрби хезмәткә ала башлыйлар [1: 97].

Рекрутлар гамәлдәге армиянең нигезен тәшкил итә, дәүләт хисабына тотыла, бердәм кием һәм корал белән тәэмин ителә.

Гаилә корып, тормыш көтәргә тиешле егетләрнең гомерлеккә йортыннан аерылуы авыр кичерелгән. Китүчеләрнең күбесе кире өенә кайта алмаган, рекрутлар яралардан, авырулардан һәм җәзалардан үлгәннәр, шуңа күрә ир-егетләрне хәрби хезмәткә озату аларны соңгы юлга озату буларак кабул ителгән. Әлеге вакыйгаларга җавап буларак, Россия территориясендә яшәүче халыкларда, ир-егетне үлемнән саклап калу максатыннан, рекрут йоласы барлыкка килгән. Билгеле булганча, һәр халыкның рухи мәдәниятендә кешенең биологик яки социаль статусын алыштыруга бәйле барлыкка килгән күчеш йолаларының (переходные обряды – *А. ван Геннеп термины*) булуы билгеле (бала туу, туй, соңгы юлга озату һ. б.). Рекрут йоласы да бу төр йолаларның берсе булып, ир-егетләрнең исән-сау әйләнеп кайтуын тәэмин итү максатыннан, халык яшәешенең бер өлешенә әверелгән һәм ритуаллар, ышанулар, фольклор текстларның берләшүе нәтиҗәсендә без бүгенге көндә солдатка озату йоласы дип атый торган йола комплексының гасырлар дәвамында яшәвенә сәбәп булган. Әйтергә кирәк, рекрут йоласы һәм аның белән бәйле фольклор – татар фольклористикасы фәнендә иң аз өйрәнелгән өлкәләрнең берсе. Әлеге йола белән бәйле халык авыз иҗаты әсәрләренә 13 томлы «Татар халык иҗаты» тупланмасының җыр томнарында, «Милли-мәдәни мирасыбыз» сериясендә чыккан китапларда, фольклорчы, диалектолог, этномузыкологларның хезмәтләрендә беркадәр игътибар бирелсә дә, солдатка озату йоласының тәртибе (повестка алу, урам әйләнү, кунак булып йөрү, озату кичәсе һ. б.), аның белән бәйле җырлар, ышанулар, ырымнар һ. б. бүгенге көнгә кадәр тулы бер комплекс буларак тикшерелмәгән.

Рекрут – татар теленә рус теле аша кергән француз сүзе (фр. *Récruter – «гаскәр туплау»*) булып, XVIII гасыр – XX гасыр башында Россия империясендә даими армиягә гаскәриләр туплау алымын һәм гаскәринең үзен атый. Татарлар арасында әлеге сүзнең «никрут» формасы киң таралган була. Пётр I үлгәннән соң, Россиядә аның кайбер тәртипләре кабат күздән кичерелә. Тарихтан билгеле булганча, патша армиясенә алынган кеше Екатерина II чорында 25 ел буена солдат хезмәтен үтәргә тиеш булса, алга таба бу вакыт – 20, 15, тагын да соңрак Александр II вакытында 6 елга калдырыла. Ике гасыр дәвамында халык җилкәсенә авыр йөк булып яткан рекрутчина Беренче бөтендөнья сугышы вакытында үзгәреш кичерә. Тарихтан билгеле булганча, бу вакытта хәрби хезмәткә алынучылар белән беррәттән сугышка яраклы барлык ир-атларны да чакыра башлыйлыр, илдә гомуми мобилизация игълан ителә.

Илдә барган вакыйгаларның халык тормышында ни рәвешле чагылыш табуын шул заманда яшәгән кешеләрнең истәлекләре буенча күпмедер дәрәҗәдә күзаллап була. Ык буенда яшәүче татарларның рекрут йоласы белән бәйле җыр текстларын өйрәнгән фольклорчы галим Риф Мөхәммәтҗанов язмалары арасында XIX гасыр ахырында

туган кешеләрнең истәлекләре шактый. Шуларның берсе Башкортстан Республикасы Шаран районы Алпай авылында өч сугышта катнашкан Якуп Игъдиевтан (1896 елгы) язып алынган. «Беренче империалистик сугышка кадәр, никрутлар булып игълан ителгәч, ике атна буена өйдән өйгә йөртеп, җыру, наз әйтеп (Ык буе татарларында рекрут җырларын «назлар» дип атаганнар. – *Л.Х. Дәүләтшина иск.*), безне сыйладылар. Авыл өчен кадерле идек. Кыңгыраулы атлар хәтәр бизәлгән, бер-бер авылны китәсе көнне генә өчәр тапкыр урадык. Кайда туктасак, шунда сый, шунда наз әйтү, елашу, гармунга бию, кочаклашып саубуллашу. Соңгы көн бигрәк ямансу, бөтен авыл, туган-тумача, ата-ана, сөйгән кызлар озата чыга. Үзем дә ул күп җыру, наз әйтеп, аз яшь түкмәдем. Авыр була иде аерылышу» [7: 22].

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында яшәгән кешеләрнең истәлекләреннән күренгәнчә, хәрби хезмәткә алынган вакытларда, татар авылларында ир-егетләрне һәрвакыт җыр белән озатканнар, өйдән өйгә йөртеп, сый-хөрмәт күрсәткәннәр. Мәҗлес атна-ун көн буе дәвам иткән. Бөтен авыл, басу капкасын чыкканчы, аларны озатып калган. Татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә төрле җыр текстлары башкарылса да, аларның барысы да туган яктан аерылу, билгесез киләчәк турында уйлану мотивларын алга чыгарган, сагыш хисе белән сугарылган.

Совет чорында хәрби бурыч мәсьәләсенә мөнәсәбәт үзгәрә: солдатка алыну, армия сафында хезмәт итеп кайту һәр ир-егетнең бурычы дип игълан ителә һәм хәрби хезмәткә озатуның тантаналы бәйрәм рухында үтә торган йолалары барлыкка килә. Әмма шул ук вакытта халыкның традицион озату йоласы да, яңа гадәтләр белән баеп, тормыш үзгәрешләренә яраклашып дәвам итә. Солдатка алынган яшьләрнең үзләре генә җыелып, һәм гаиләдәге якыннары, сөйгән ярлары белән бергә хушлашу мәҗлесләре үткәрүләре менә шуннан килә.

Горур совет солдаты исемен йөртүче хәрбиләр тормышында тыныч вакытлар да, аянычлы сугышлар да булып торган. Аларның иң куркынычы – әлбәттә, Бөек Ватан сугышы. Бу чорда сугышка китүчеләрне озату үзгә төс ала, чөнки ил күләмендә дошман белән көрәшкә бөтен халык күтәрелә. Халкыбызның күп гасырлык тәҗрибәсен туплаган иҗаты сугыш чорларында үзгәреш кичерә, яңа шартларга җайлаша һәм үсештән туктамый. Халык йоласына туры китереп, сагышмоңнарын авыл көенә салып, туган ягы, якыннары белән саубуллашып фронтка киткән ир-егетләр сугыш кырында да рухи ихтыяҗларын фольклор әсәрләре аша канәгатьләндерәләр, җыр, бәет, мәзәк, тапкыр сүзләр телдән телгә күчеп таралалар. Бу чорда борынгыдан килгән һәм тирән кайгы-хәсрәт белән сугарылган җырлар алгы планга чыга, сагыну хисе халык иҗатын тулысы белән биләп ала.

Солдатлар китә – озатаек,
Басу капкаларын чыкканчы;

Озата бардым, карап калдым,
Күз керфеккәйләрем талганчы.

Солдатлар китә сайланып,
Билләренә каешлар бәйләнеп;
Исәннәр йөрсәк, бер кайтырбыз
Туган-үскән җирләргә әйләнеп.

Атларның җиктем мин карасын,
Һич белмәдем кая барасын;
Барасы җирләргә барып җиткәч,
Җәлләмәгез язу карасын [10: 28].

Бөек Ватан сугышы тәмамланган, илгә тыныч тормыш килгән, шулай да ир-егетләр ел да хәрби хезмәткә алынып торган, солдатка озатулар заманага бәйле үзгәрешләр кичереп, нигездә, традицион рәвештә дәвам иткән. Совет чоры узганнан соң, хәрби сафларда күп нәрсә үзгәрә. Бүгенге көндә хезмәт итү вакыты бер ел тәшкил итсә дә, армиягә озату йоласы хәзер дә яши, ватаныбызның төрле почмакларында бу йоланың үз традицияләре саклана.

Күрүебезчә, ир-егетләрне хәрби хезмәткә алуның инде күп гасырлык тарихы бар. Россиядә яшәгән халыкларның һәрберсенә кагылган бу күренеш аларның милли-мәдәни үзенчәлекләрен үз эченә алган солдатка озату йоласы формалашуга китергән, аның гасырлар буена калыплашып килгән тәртибен, ышану-гадәтләрен саклаган хәлдә дәвамлылыгын тәэмин иткән. Биредә гасырдан гасырга күчә килгән йола-гадәтләрнең, мифологик ышанулар белән сугарылып, бүгенге көнгә кадәр килеп җиткән төп үзенчәлекләрен барлап, солдатка озату йоласының хәзерге яшәешенә тукталып үтик.

Бу йола иң элек кеше күзе күрмәгән, кеше аягы басмаган ерак һәм куркыныч юлга чыгып китү процессын ничек тә җиңеләйтү, егетнең исән-сау әйләнеп кайтуын тәэмин итү максатыннан башкарыла. Чит якка, ерак юлга чыгып китәргә тиешле кеше, аның нәкъ менә солдат булуы да мәҗбүри түгел, һәрвакыт нindидер йолалар аша үтәргә тиеш, чөнки ул үз өеннән чит юлга чыга. Ә юлга чыгучы кешенең һәр адымы ышанулар белән бәйле. Тупсадан уң аяктан атлап чыгу, киткән кеше артыннан идән себерергә ярамау, кире әйләнеп кермәү, утын күтәреп керү – болар барысы да я юлчы, я аны озатып калучылар тарафыннан башкарылырга тиешле мөһим гамәлләр.

Халык ышануларында юл, бигрәк тә билгесез юл, һәрвакыт куркыныч, кеше аягы басмаган, түбән рухлар, зыян салучы көчләр яши торган җир буларак тасвирлана. Юлның үлем, бәла-каза китерә торган җир булуы яңа йортка нигез сайлау йолаларында аеруча ачык күренә. Татар халкы өйне беркайчан да тыкрык, юл, җиде юл чатына салмый, чөнки мондый йортта яшәсәң, кайгы киләсе көн кебек ачык. *Тыкрыкта өй салырга ярамый. Чат бит ул. Яшәп булмый андый йортта. Бетә андый нигез, диләр. Безнең берәү төзегән иде тыкрыкта. Үзе*

*озак та тормады, үлеп китте. Инде аннан соң әллә ничә гаилә торып карады. Берәү дә яши алмый. Тыныч түгел анда* (И.В. Иванов (1929), Татарстан Республикасы Питрәч районы Керәшен Сәрдәсе авылы). Юл буена салынган йортларның тынычсыз булуы халык мифологиясендә юлда очраган мифологик персонажлар белән бәйле. Адаштыра торган урыннар да күбесенчә берничә юл кисешкән җиргә туры килә, шуңа күрә юлда җен зәхмәте кагылмасын, бәла-казалар килмәсен, юлчы өенә кире әйләнеп кайтсын өчен, билгеле бер йолалар үткәрелә. Һәр очракның (солдатка китү, соңгы юлга озату, күрше авылга кунакка бару, эш белән ерак юлга чыгу һ. б.) үз йола-гадәтләре бар, әмма аларның мәгънәсе бер үк: һәрберсе кешенең исән-сау әйләнеп кайтуын тәэмин итүгә, таныш булмаган җиргә әзерләп чыгарып җибәрүгә юнәлтелгән.

Солдатка озату йоласы да иң беренче чиратта юл семантикасына бәйле булып, төрле этаплардан оеша. Элек-электән килгән гадәт буенча, солдатка китәргә әзерлек повестка алуга ук башлана. Бу вакытта авылның һәр кешесе әлеге йолага үз өлешен кертә. Хәрби хезмәткә алынучы егетләр, бергә җыелып, бәйрәм киемнәрендә, көн саен диярлек рекрут җырларын башкарып, гармун белән урам әйләнәләр. Әлеге гадәтнең көндәлек тормыштан инде әкренләп югалуы күзәтелсә дә, гармун тартып, авылны яңгыратып җырлап йөрү традициясе әле бүген дә очрый. Рекрут җырлары төрле булып, гадәттә, бер буыннан икенчесенә күчә килә һәм күп вакытта авыл көенә башкарыла. Аларда туган яктан, туган йорттан, әти-әнидән аерылу мотивлары да, сагыш, киләчәк тормыш өчен борчылу да, батырлык, өмет хисләре дә чагыла. Татарлар яшәгән кайсы төбәкне алсаң да, рекрут җырлары халык хәтерендә саклана, буыннан буынга күчә. Әйтик, Марий Эл Республикасында бүгенге көндә дә яшьләр авыл көенә түбәндәге җырларны җырлап урам әйләнәләр.

Арыслан айга сикерә,
Каршысында тал булса.
Кайгырма, егет, кайгырма,
Газиз башың сау булса.

Әллә кайдан күренеп тора
Магистраль ташлары.
Ал булса да, гөл булса да,
Калды ич Куян яклары.

Солдатларга аш бирәләр
Калай тәлинкә белән.
«Смирно», диеп кычкыралар
Калын тавышлар белән.

Әй, дусларым, беләсезме,
Без бит Куян яклары.
Башларымның төрле уйлар
Уйлый торган чаклары.

Алма бакчасын чабыгыз,
Үткен булса чалгыгыз.
Су өстендә дулкын ничек,
Безнең шундый чагыбыз [6: 302].

Истәлекләргә караганда, XX гасыр урталарында әле бу хәрәкәткә үз авылы гына түгел, китәсе егетләр яшәгән күрше авыллар да кушылган, бер авылдан бер авылга барып, урам әйләнү гадәте булган. Армиягә китәсе егет иң элек йорттан йортка кереп саубуллашып йөри, аңа бүләккә дип әзерләп куелган кулъяулык, сөлгеләр җыя. Берничә атнага сузылган урам әйләнү белән беррәттән, авылдашлары егетләрне кунакка да чакырып ала. *Бик матурлап гармун уйнап урам әйләнәләр иде. Көн дә урам әйләнәләр иде, җырлап, китә торган кеше. Мин кичерәк вакытта берәмләп-берәмләп кунакка йөртәләр иде китә торган кешене. Туган-тумачасы, дус-ишләре шулай итеп йөртә торганнар иде* (Газизова Р.Г. (1919), Марий Эл Республикасы Бәрәңге районы Куян авылы). *Повестка алгач, күрше-күлән, туганнар кунакка чакыра инде. Я үзеңне генә, я дустың белән бергә. Чәй эчкәннән соң, юл хәере бирәләр* (Дәүләтшин И.З. (1976), Татарстан Республикасы Мамадыш районы Түбән Козгынчы авылы). Шул рәвешле, рекрутлар үзләрен авыл кешеләреннән аерып куялар, ягъни икенче социаль статуска күчүләрен күрсәтәләр һәм авылның үзе, авылдашлары белән саубуллашалар.

Хәрби хезмәткә китәсе егет авыл социумында үз урынын билгеләп, социаль статусын күрсәтеп кенә калмый, бәлки авыл тирәсендәге сакраль мәгънәгә ия объектлар белән дә саубуллашып, үз ният-максатларын аңлатып, алдагы юлының уңышлы булуын тәэмин итәргә тырыша. Билгеле булганча, татар халык мәдәниятендә изге урын төшенчәсе шактый әһәмияткә ия. Изге дип чишмә дә, кабер дә, таш та, агач та саналырга мөмкин. Әлбәттә, бу очракта сүз очраклы объект турында түгел, ә бәлки могҗизасы булган яисә могҗизалы хәлләр белән бәйле объект турында бара. Бу төр объектларга карата халык традициясендә билгеле бер ритуаллар һәм таләпләр да яшәп килә: изге урын янына даими барып, аны карап, чүп-чарлардан арындырып тору; гомумән авыл яисә аерым бер кеше авыр хәлгә тарыса, изге урынга барып, бу хәлдән котылдыруны сорау; аның янында эшләргә рөхсәт ителгән һәм тыелган гамәлләр комплексы – болар барысы да авыл социумында билгеле кагыйдәләр.

Солдатка китәсе егетләр дә әлеге күренештән читтә калмый. Ерак юлга кузгалырга тиешле рекрут, китәренә берничә көн кала, изге урын янына барып, үз теләкләрен әйтә, Ходайдан исән-сау әйләнеп кайтырга ярдәм итүен сорый. Татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә очраган изге урыннарның күбесе, риваятьләрдән күренгәнчә, ислам динен таратып йөргән әүлия/яхшылар/шәех/ишан каберләре белән бәйле. *Менә безнең Нурислам армиягә китәр алдыннан Ташамышка Акташына садака калдырам дип керде.... Аны өйрәттем. Башта бисмилланы әйт, аннары дога язып бирдем, шуны укырсың, дидем.*

*Аннары теләкләрен әйтә инде. Изге юл сорый. Садакасын сала. Белмичә бармыйсың инде, белеп барасың* [4: 5]. Әлеге таш Татарстан Республикасының Биектау районы Казаклар авылы янында урнашкан һәм, халык ышанулары буенча, бу урында изгеләр җирләнгән дип исәпләнә, шуңа да авырлык килгәндә, Акташ янына барып, садака бирү – авылда киң таралган күренеш.

Китәсе көн якынлашкан саен, рекрутларның аралашу урыны әкренләп авыл җирлегеннән бер йорт даирәсенә күчә. Биредә иртәгә китәсе дигән көнне кичтән озату кичәсе (провод, озату боткасы, озату ашы һ. б.) үткәрелә. Озату кичәсенә егетнең дуслары, сөйгән кызы, туган-тумача, күрше-күлән чакырыла. Табынга төрле-төрле ризыклар чыга, яшьләр җырлап-биеп күңел ача. Кайбер якларда махсус ризык – *озату боткасы* әзерләү гадәте булганлыгы да билгеле. Нинди дә булса ярмадан тәмле итеп ботка пешерелә, аның уртасына, күз ясап, сары май салына. Ритуаль ризык буларак аңланган һәм төрле йолаларда төрле вариантларда тәкъдим ителгән ботка табынның төп сые буларак уртада тора, аннан һәр кеше авыз итәргә тиеш була. Кунаклар ботка ашарга утыргач, китәсе егет озату җырын башлап җибәрә.

Боткалар да пешкән, майлар сипкән,
Ашыйсы килми, туганнар, нишлим соң.
Атлар гына җиккән, капка ачкан,
Китәсе килми аерылып, нишлим соң.

Ишектән лә чыктым, мин таелдым,
Әти-әни сездән үк аерылдым.
Капкадан ла чыктым, мин таелдым,
Бар туганнар, сездән үк аерылдым.

Карлыгачлар кара, муены ала,
Югары ла очып югала.
Бәхетле лә бала илдә кала,
Бәхетсезләр китеп лә югала.

Тәрәзәне ачтым, мин сызгырдым,
Болындагы печәннәр кипсен дип.
Болындагы печәннәр ай кипте инде,
Безгә китәр вакытлар җитте инде.

Җырлап бетергәч, егетне өстәл тирәли кояш уңаена өч тапкыр әйләндерәләр, ата-анасы, әби-бабасы бәхилли, теләкләрен тели [2: 232].

Озату кичәсе үткәргәннән соң, икенче көнне иртән егетнең исән-имин әйләнеп кайтуын тәэмин итә торган магик йола-гадәтләр башкарыла. Өйдән чыгып китәр вакыт җиткәч, өй эчендәге кешеләр өстәл артына җыелалар. Егетнең әнисе алдан ук әзерләп куйган ризыгын улына каптыра һәм махсус урынга сакларга куя. Татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә әни кулыннан алына торган ризыклар, аларның саклану урыннары да күптөрле. *Өстәл янында утырганда, әни бер телем ипи бирә, аны тешлисең дә кире әнигә бирәсең, ул аны пич өстенә*

*куя. Кайтканчы тора инде ул шунда* (Татарстан Республикасы Мамадыш районы Түбән Козгынчы авылы). *Энемнең сыныгын кыстырып куйган идек. Кибән башын кисеп, бер тешли дә, матчага элеп куясың* (Татарстан Республикасы Биектау районы Өлә авылы). *Озатыр алдыннан сыек кына камыр ясыйбыз. Егет шунда кулын тыгып, матчага кулын баса, аның кул эзен үзе кайтканчы саклыйбыз* (Татарстан Республикасы Апас районы Багыш авылы). *Ишектән чыгар алдыннан өч йотым сөт, өч кабым аш ашый. Калган ашын өйдә калган киеменең кесәсенә сала, һәм ул, үзе кайтканчы, шунда тора* (Төмән өлкәсе Төмән районы Турай авылы). *Китәсе көнне терлек суясың. Каз суясыңмы инде анда, тавык суясыңмы. Шуның ботын бирәсең инде икмәк белән. Аны кимереп бетерсә – сөяген, кимереп бетермәсә, ризыгын чорнап-төйнәп куябыз инде сандык төбенә* (Татарстан Республикасы Питрәч районы Янсуар авылы). Татар халкының бу гамәлләре артында «киткән кеше исән кайтсын дип, ризык һәрвакыт теләп тора» дигән ышану ята.

Мич яки өстәл яныннан егетнең кеше күзе күрмәгән чит якларга юлы башлана, әмма аңа әле, юлга чыкканчы, берничә чикне үтәргә кирәк. Бу чикләрне ничек үтүенә карап, аның исән-сау әйләнеп кайту-кайтмавы да тәгаенләнә. Иң беренче чик – ул ишек тупсасы, шуңа күрә тупса аркылы чыкканда саклау магиясе актуальләшә. Татарстан Республикасының Питрәч районында егетне, «Исән-сау йөреп кайт» дип әйтеп, тышкы ягы белән өскә каратып салынган тун аркылы атлатып чыгаралар. Саратов өлкәсендә яшүче татарлар рекрутны тупса аркылы йөзе белән түгел, ә киресенчә «йөзе белән кайтсын дип», аркасы белән чыгаралар. Төмән өлкәсенең Турай авылында исә ана кеше, «үз кулым белән озаттым, үз кулым белән каршы алырга насыйп булсын» дип, улын күкрәгеннән, аркасыннан ике кулы белән сыпыра. Шул ук өлкәнең Янтык авылында теләү үткәрү гадәте саклана. Егет китәсе көнне иртәдән тавык суела һәм аның чыгып китәр вакыты җиткәч, тавыкны рекрутның башы, култык асты, биле тирәли өч кабат әйләндерәләр. Ишектән чыгарганда, күп якларда егетнең кесәсенә «Үзеңнең туфрагың белән йөре, үзеңнең туфрагыңа кайтып бас», дип, туфрак салынган кечкенә янчык салып җибәрәләр. Бары шушы ым-хәрәкәтләрне башкарганнан соң гына, ана күңелендә улының исән-имин кайтачагына ышаныч туа.

Йорт, ихата эченнән саубуллашып чыгып киткәннән соң, егетләр һәм аларны озатучылар соңгы чиккә – басу капкасына таба юл тоталар. Белүебезчә, элек авылга керә торган урында капка торган һәм аның каравылчысы булган, һәр килгән-киткән кеше шуннан исәнләшеп-саубуллашып узган. Бу үзенә күрә «авыл дөньясына» керү урыны булып исәпләнгән. Бүгенге көндә авыл капкалары инде булмаса да, авылга барыбер билгеле бер җирдән генә кайтып керергә һәм чыгып китәргә мөмкин. Бары шушы чикне узганнан соң гына, рекрутлар авыл белән хушлашалар һәм чын мәгънәсендә юлчыга

әвереләләр. Шуңа да өйдән басу капкасына кадәрге юл үтү магик гадәтләр белән сугарыла.

Бу аралыкны бары китәсе егет үзе, аның әнисе һәм якыннары гына уза ала. Әмма авылның башка кешеләре бу йолага катнашмый дигән сүз түгел. Аларның да бу көнне үз вазифалары бар. Күп очракта авылда яшәүчеләрнең барысы да диярлек капка төбенә чыгып, хәерле юл теләп, юл хәере биреп, китүчеләрне озатып кала. Мамадыш районында таралыш тапкан гадәт буенча, кызлар чиккән кулъяулык бирәләр һәм егетләр аларны бер-берсенә бәйләп, муеннарына урыйлар. Басу капкасыннан чыгып киткәндә, егет кеше озын бау булып сузылган кулъяулыкларны, үзе кайтканчы саклансын өчен, анасына биреп калдыра. Бу кулъяулыклар егетнең туган йортына таба сузылган юлын символлаштыра һәм аны туган нигезе белән бәйли. Саратов татарларында кулъяулыкны басу капкасына, я булмаса авыл исеме язылган тактага бәйләп калдыру гадәте киң таралган [3: 49]. Аксубай якларында рекрут өйдән өйгә кереп, саубуллашып, авылдашларыннан фатиха алып чыгарга тиеш. Бу йола барышында һәр өйдән кулъяулык бирү гадәте дә бар. Егет бу кулъяулыкларны бер-берсенә бәйләп, муенына чорный бара. Авылдан чыгып киткәндә, аларны басу капкасына яисә шунда үскән агачка ныклап бәйләп китәргә тиеш була. Егет кайтканчы кулъяулыкның өзелеп төшмәве – аның туган җиренә исән-имин әйләнеп кайтачагына бер ишарә буларак кабул ителә. Шушы юл белән егетләр туган нигезгә бәйлелекләрен символга әйләндереп, ерак юлга чыгып китәләр һәм беренче тукталышка – военкоматка юл тоталар. Военкоматка кадәр хәрби хезмәткә китүче егетне туганнары, дуслары озата бара. Сугыш чорымы, тыныч вакытмы – кайчан гына булса да, җыр-бию туктамаган, хәрби хезмәткә китүче ир-егетләр авыл көен уйнап, тирә-якны яңгыратып, моң-зарларын җырга салып, юлга чыккан.

Сау бул, Ярмәк, сау бул, Ярмәк,
Юкәле тауларың белән.
Сау бул, Ярмәк, рәхәт яшә лә
Калган яшьләрең белән.

Әткәем-әнкәем, сау булыгыз,
Еллар кайтмый улыгыз.
Бу китүдән кайта алмасам,
Туганнарым, сау булыгыз.

Сандугачлар килгән безгә,
Китәрләрме икән көзгә?
Язгы сабантуйларына
Кайтырбыз микән без дә?..

Каршыбызда Юкәле тау
Тагын яшәрер әле.
Ходай гомерләрне бирсә,
Бергә яшәрбез әле [8: 107–108].

Җыр-моң, гармун көе белән үрелеп барган бу шау-шулы күренеш военкомат ишегалдына кадәр дәвам итә, аннан инде якыннары, егетне калдырып, өйләренә кайтып китә.

Авыл капкасыннан егетне һәм аны военкоматка кадәр илтүчеләрне озатып җибәргәннән соң, ана кеше һәм якыннары өйгә әйләнеп кайталар һәм йорт беркадәр вакыт гомум авыл яшәешеннән читләшеп тора. Егет чыгып киткән йорттан беркемгә бернәрсә бирмиләр, өстәлне җыештырмыйлар, идән себермиләр. Татарлар яшәгән күп төбәкләрдә киткән кеше артыннан, «озын гомерле булсын» дип, утын яисә чыра күтәреп керү гадәте киң тарала. Себердә исә, гадәттә, ике чыра алып керәләр һәм берсен, егет кайтканчы дип, алып куялар. Ул исән-сау әйләнеп кайткач, күсәйтен чәе дип аталган мәҗлескә чәйне шушы чыра белән кайнаталар [9: 453]. Бу гадәтләр киткән кешенең туган нигезе белән бәйләнешен саклауга юнәлтелә, һәм юлчы «суны чыкканчы», йортның шушы статусы саклана. Әлеге сүз-формула да борынгы ышануларга барып тоташа. Элек ана кеше баласын беренче суга кадәр озатып бара торган булган, бары шуны кичкәннән соң гына, егет авылдан чыгып киткән дип исәпләнгән. Бүген исә андый гадәт гамәлдән төшеп калган, әмма «суны чыкканчы» дигән сүз һаман да халык күңелендә яши һәм, нигездә, бер көн дигәнне аңлата. Шулай итеп, егет киткәннән соң, бер көн тирәсе вакыт узгач, йорт гадәттәге тормышы белән яши башлый.

Хәрби хезмәткә киткән ир-егетнең исән-имин кайтуын солдатка озату йоласы гына тәэмин итми, йөрәк парәсе читтә йөргән кешенең һәр гамәле аны көтүгә, аның исән-имин кайтуын тормышка ашыруга юнәлдерелгән була. Көндәлек искә алулар, теләкләр белән беррәттән һәр җирлекнең үзенең калыплашкан йола-гадәтләре дә яшәп килә. Әйтик, Татарстанның Саба районы Олы Шыңар, Лаеш районы Атабай авылларында Сабан туен үткәргәндә нәзер аты, нәзер атын котлау дигән гадәт билгеле. Билгеле булганча, Сабан туенда иң беренче килгән атка иң мәртәбәле бүләкләр бирелә, аның исеме теллләрдән төшми. Бу якларда халык соңга калып килгән ат турында да онытмый, ул гарьләнеп елый дип ышана. Шуңа да соңга калып килгән атка атап, алдан ук ниндидер эшнең уңышлы килеп чыгуына ышанып, вәгъдә билгесе – махсус бүләкләр бирелә. Нәзер аты күп вакытта беренче килгәненә караганда да күбрәк бүләккә ия була. Әлеге бүләкләр арасында махсус адарынып, армиядә йөрүче улы исән-сау кайтсынга, озак вакытлар авырып ятучы туганы терелсенгә һ. б. шундый очраклар уңышлы тәмамлансынга, алдан ук атап, нәзер итеп бирелгәннәре дә күп була. Гомумән алганда, ниндидер эшне башкару алдыннан, уңай килеп чыккан очракта, үз-үзеңә берәр йөкләмә үтәргә вәгъдә бирү, ягъни нәзер әйтү гадәте – татарлар арасында киң таралган күренеш.

Югарыда әйтелгәннәрдән күренгәнчә, солдатка озату йоласы гасырлар дәвамында калыплашкан ритуалларны, аның белән бәйле ышану, ырым, җыр текстларын берләштереп, тулы бер йола

комплексы хасил итә. Бу йоланың бер генә сүзе дә, ымы, хәрәкәте дә мәгънәсез түгел, аларның һәрберсе егетнең туган нигезе белән бәйләнешен өзмичә, исән-сау кире әйләнеп кайтуын тәэмин итә һәм мифологик ышануларга, халыкның тормыш тәҗрибәсенә нигезләнә. Бүгенге болгавыр заманда да солдатка озату йоласы үзенең төп калыбын саклый һәм йола-гадәтләрнең бер буыннан икенче буынга күчүен тәэмин итә.

**Әдәбият**

1. *Абдуллин Х.М.* Татары в регулярной армии в период Отечественной войны 1812 г. и заграничных походов 1813–1814 гг. // Из истории и культуры народов Среднего Поволжья. 2024. Т. 14. № 3. С. 96–107.

2. *Баязитова Ф.С.* Керәшеннәр: Тел үзенчәлекләре һәм йола иҗаты. Казан, 1997. 248 б.

3. *Давлетшина Л.Х.* Мир вокруг нас: о современном состоянии мифологической традиции татар. Казань: ИЯЛИ, 2024. 120 с.

4. *Завгарова Ф.Х.* Типология сюжетов почитания культового камня у татар Заказанья // Татар халык иҗаты. Фәнни эзләнүләр һәм фольклор үрнәкләре. (Фәнни конференцияләр материаллары җыентыгы). Өченче китап. Казан, 2007. Б. 4–11.

5. *Кормина Ж.В.* Проводы в армию в пореформенной России. Опыт этнографического анализа. М.: Новое литературное обозрение, 2005. 376 с.

6. *Мөхәмәтшина Л.М.* Күңелдәге җырлар // Милли-мәдәни мирасыбыз: Марий Эл татарлары. Бәрәңге. Казан, 2021. Б. 288–311. (Фәнни экспедицияләр хәзинәсеннән).

7. *Мөхәммәтҗанов Р.М.* Башкортостан Ык буе татарларының йола иҗаты. Практик эш материаллары. Уфа, 1984. 72 б.

8. *Мөхәммәтҗанова Л.Х.* Самара татарларында заман фольклоры // Милли-мәдәни мирасыбыз: Самара өлкәсе татарлары. Казан, 2015. 360 б.

9. Татар халык иҗаты: 25 томда. 2 т.: Йола фольклоры / төз., текст, иск. һәм аңл. әзер., кереш сүз авт. Л.Х. Дәүләтшина. Казан: Татар. кит. нәшр. 2022. 541 б.

10. Утлы еллар кайтавазы: Бөек Ватан сугышы чорында татар халык иҗаты. Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. 199 б.

***Дәүләтшина Ләйлә Хәсән кызы,***
*филология фәннәре докторы, ТР ФА Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык иҗаты бүлеге мөдире*

***Давлетшина Лейла Хасановна,***
*доктор филологических наук, заведующий отделом народного творчества Института языка, литературы и искусства имени Г. Ибрагимова АН РТ*
*leyla.davletshina@yandex.ru*